**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

20.04.2022 № 458

Территорияне планлаштыру
документларын эшләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45, 46 статьялары нигезендә территорияләрне тотрыклы үстерүне тәэмин итү, линия объектларын төзү һәм урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләре чикләрен билгеләү максатларында «СТРОЙАРТ» ЧҖҖнең тәкъдимен карап, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы территориясендә урнашкан «Татнефтепром-Зүзәйвнефть» АҖнең «1310, 1310Б номерлы скважиналарның кустларын төзекләндерү» линияле объектында «СТРОЙАРТ» ҖЧҖенең территорияне планлаштыру һәм ызанлау проектын үз акчалары исәбеннән әзерләү турында тәкъдимен кабул итәргә.
2. Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегенә физик һәм юридик затларның территорияләрне планлаштыру һәм ызанлау проектын әзерләү тәртибе, әзерләү сроклары һәм эчтәлеге турында тәкъдимнәрен кабул итәргә һәм карарга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р.Хәмзин